## ЯЗЛАРДА

*сүзләре – Равил Гөзәиров һәм Шамил Сагаутдинов,*
*көе – Шамил Сагаутдинов*

1. Сибелә кояш нурлары,
   Ишетелә шат авазлар.
   Яшәртеп бөтен дөньяны,
   Килде тагын матур язлар.

**Кушымта:**

Язларда,
Җир ямьләнә язларда,
Очып кайта казлар да,
Сагынып илләрен.

Язларда
Туган сөю, назлар да
Гомерлек булса иде,
Бәгырем!
} 2 тапкыр

2. Уянды урман, кырлар да,
   Калын карлар эреп акты,
   Ямьләндереп тирә якны
   Умырзая чәчәк атты.

**Кушымта.**

3. Бүләк итик сөйгәннәргә
   Беренче гөл бәйләмнәрен.
   Уйнап-көлеп каршы алыйк
   Язның матур бәйрәмнәрен!

**Кушымта.**

**По весне**

Песня о самом светлом времени года, когда в сердцах пробуждаются ростки прекрасного чувства...

*По весне*
*Мир преображается:*
*Птицы возвращаются,*
*И земля в цвету.*
*По весне*
*Верю не напрасно я,*
*Что любовь прекрасную*
*Я найду!*